КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 март г.Казань № 185

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 22 ноябрь, 646 нчы; 2009 ел, 24 февраль, 101 нче; 2009 ел, 9 ноябрь, 776 нчы; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2010 ел, 9 июнь, 454 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1038 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 21 февраль, 125 нче; 2011 ел, 25 март, 220 нче; 2011 ел, 13 апрель, 291 нче; 2011 ел, 29 июль, 613 нче; 2011 ел, 13 август, 674 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 30 июль, 646 нчы; 2013 ел, 9 февраль, 80 нче; 2013 ел, 14 март, 163 нче; 2013 ел, 7 октябрь, 730 нчы; 2013 ел, 30 ноябрь, 940 нчы; 2014 ел, 5 февраль, 64 нче; 2014 ел, 29 март, 201 нче; 2014 ел, 11 ноябрь, 853 нче; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2015 ел, 3 июнь, 401 нче; 2015 ел, 20 август, 610 нчы; 2015 ел, 2 октябрь, 733 нче; 2016 ел, 26 февраль, 121 нче; 2016 ел, 25 ноябрь, 874 нче; 2017 ел, 9 февраль, 74 нче; 2017 ел, 10 июль, 468 нче; 2017 ел, 6 ноябрь, 846 нчы; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3.3 нче пунктның 3.3.1 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә:

Татарстан Республикасы территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклауның төп юнәлешләрен билгеләүдә катнаша;

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе экологиясен үстерү өлкәсендәге федераль сәясәтне тормышка ашыруда катнаша;

үз вәкаләтләре чикләрендә әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актлары проектларын эшли һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә кертә, шулай ук аларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив хокук актларын, инструктив-методик документлар эшли һәм кабул итә;

Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары белән берлектә, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын, шулай ук әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча башка норматив хокук актларын эшли һәм тормышка ашыра;

дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар үтәлешен тәэмин итү, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге таләпләрне, шул исәптән нормативларны һәм норматив документларны үтәүне, шулай ук экология иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы территориясендә булган теләсә кайсы милек рәвешләрендәге хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларында төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экология иминлеген тәэмин итү өлкәсендә күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру кысаларында әйләнә-тирә мохит объектларының һәм әйләнә-тирә мохиткә пычратучы матдәләрне чыгару һәм ташлау чыганакларының пробаларын сайлап алу, тикшерү (сынау), үлчәүне үткәрә;

Министрлыкның төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары (Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге дәүләт инспекторлары) исемлеген билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм раслау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозып гамәлгә ашырыла торган хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлекне билгеләнгән тәртиптә чикләү, туктатып тору һәм (яки) тыю турындагы таләп белән (федераль дәүләт экология тикшерүендә тотылырга тиешле объектлардан тыш), шулай ук, табигатьне саклау законнары үтәлешен тәэмин итү максатларында, билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендәге башка таләпләр белән судка мөрәҗәгать итә;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарны бозу аркасында әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар кертә;

әйләнә-тирә мохиткә йогынты ясауга икътисадый бәя бирүне, республика территориясенең экология паспортын булдыруны гамәлгә ашыруны оештыра;

үз вәкаләтләре чикләрендә төбәк дәүләт экология күзәтчелеге нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларны анализлауны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

тиешле елга Татарстан Республикасы бюджеты турындагы закон проектын эшләүдә, Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен оештыруда һәм аны үтәүдә катнаша;

уңай әйләнә-тирә мохитне саклауны һәм экология иминлеген тәэмин итүне гарантияләп, әйләнә-тирә мохиткә хуҗалык эшчәнлеге һәм башка эшчәнлек йогынтысын дәүләт тарафыннан җайга салуны законнар нигезендә гамәлгә ашыра;

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә башка вәкаләтләрне законнар нигезендә гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокук актлары белән билгеләнгән тәртиптә территорияләрне планлаштыру документларын карауда катнаша;

әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә тотылырга тиешле объектларның төбәк дәүләт реестрын алып бара;

төбәк дәүләт экология күзәтчелегендә тотылырга тиешле объектларда хуҗалык эшчәнлеген һәм (яки) башка эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлардан, индивидуаль эшмәкәрләрдән җитештерү экология күзәтчелеген оештыру турында һәм аның нәтиҗәләре хакында хисаплар кабул итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин